ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**« 30 » декабрь 2019 ел** **№ 37**

**"Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Наласа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 октябрендәге 96 номерлы карары нигезендә, 16.11.2019 №1, 17.11.2019 №2 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Наласа авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән **«Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә** гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнарның күпләп җыелу урыннарында мәгълүмати стендларда түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Наласа авылы, М.Вахитов урамы, 64 йорт; ТР, Арча районы, Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт.

3. Наласа авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 нче елның 22 нче ноябрендә чыккан 58 нче номерлы "Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында» гы карарын көчен югалткан дип танырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Наласа авыл
җирлеге башлыгы Шакирова И.Р

Наласа авыл җирлеге
башкарма комитетының
30.12. 2019 ел, №37
карарына
1 нче кушымта

**"Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип "Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, аларның җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдергән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2020 елның 21 февраленә кадәр башкарыла.

3. Аерым категория гражданнар:

а) тумыштан инвалид гражданнар өчен түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Түбәндәге нигезле сәбәпләр:

а) гаилә әгъзасының үлеме (ата-ана, хатыны/ире, балалары),

б) янгын яки башка табигый бәла-казалар нәтиҗәсенә зыян килү очраклары булганда, гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан артмаган срокка кичектереп тору каралырга мөмкин.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы гражданнар игътибарына (http://pravo.tatarstan.ru/) сайтында бастырып чыгару юлы белән, Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмати стендларда урнаштыру, шулай ук кул куйдырып язмача яисә почта аша юллама җибәрү юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан җыелган акчалар **«Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең** шәхси счетына керә.

7. Түләүләр гражданнар тарафыннан физик затлар кушуы буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия исәп-хисап оешмалары аша, почта аша акча күчерүне гамәлгә ашыра торган оешмалар (исәп-хисап оешмалары), **«Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты кассасы** аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

8. Түләү фактын раслый торган документ булып кассага керем ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Наласа авыл җирлеге
башкарма комитетының
30.12.2019 ел, № 37
карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № ______

"Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең ф.и.а.и.______________________________________________
Адресы:________________________________________________________

__________________________________________________________________ниге зендә Сезгә ______________________________________________________ чараларны тормышка ашыру өчен ______________________________срокка кадәр ____________ суммада түбәндәге реквизитлар буенча бер тапкыр түләү башкарырга кирәк:

БИК алучы банк ________________________
Сч. № __________________________________
Счет алучы № ___________________________
ИНН ______________________________________
КПП ______________________________________
КБК _________________ОКАТО_________________

Түләүнең билгеләнеше
__________________________________________________________________

Җитәкче _________________ ______________________________________
(имза)

Мөһер урыны

------------------------- кисү линиясе -------------------------

Хәбәр (хәбәрнамә) № _________________ «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетына ___________ сум күләмендә үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең ф.и.а.и.______________________________________________
Адресы: __________________________________________________________
Алдым «___» _________________ 20__ ел ___________________________
(имза/түләүченең ф.и.а.и.)

*Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгәндә, тутырылган корешок Наласа авыл җирлеге Башкарма комитетында кала*